| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 05.02.2026 | Баулы шәһәре | № 22 |

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2021 елның 22 октябрендәге 39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2021 елның 22 октябрендәге 39 номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының 2021 елның 14 декабрендәге 48 номерлы, 2023 елның 25 маендагы 98 номерлы, 2025 елның 28 ноябрендәге 14 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктта 4) пунктчаның дүртенче абзацында «,проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш;» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, комиссия рәисенә йөкләргә.

Баулы шәһәре мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров